ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                    КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

Югары Ослан муниципаль районы буенча
Халыкара коррупциягә каршы көрәш
Көненә багышланган чаралар
Планын раслау турында

Коррупциягә каршы караш формалаштыру, гражданнарның хокук аңы дәрәҗәсен күтәрү һәм хокукый культурасын күтәрү бурычларын хәл итү максатларында һәм Халыкара коррупциягә каршы көрәш көнен әзерләү һәм үткәрү белән бәйле рәвештә:

1. Югары Ослан районы территориясендә 2018нче елның 19нчы ноябреннән 9нчы декабренә кадәр Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган чаралар үткәрергә.

2. Югары Ослан муниципаль районы буенча коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган чаралар Планын расларга (алга таба - План, 1нче кушымта).

3. Планда каралган чараларны җаваплы башкаручы булып торучы, милек рәвешенә бәйсез рәвештә, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләренә План чараларын әзерләүне һәм уздыруны оештырырга тәкъдим итәргә.

4. «Волжская Новь» газетасы редакциясе» филиалының «Татмедиа» АҖ баш мөхәррирена План чараларын «Волжская Новь» район газетасында яктыртуны тәэмин итуне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе И.Н.Гыйләҗиевкә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы                    М.Г. Зиатдинов

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының
_____________ ____ номерлы күрсәтмәсенә
1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы буенча Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган чаралар Планы (9 декабрь)

| № | Чара | Үткәрү датасы һәм вакыты | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган блог-сораштыру (халыкны сораштыру). | 2018нчы елның 19нчы ноябреннән 23нче ноябренә кадәр | «Татмедиа» ААҖ «Волжская Новь» газетасы редакциясе |
| 2. | Гражданнар күпләп була торган урыннарда, уку йортлары биналарында, авыл җирлекләре территорияләрендә коррупциягә каршы реклама эшләү һәм урнаштыру. | 2018нчы елның 19нчы ноябреннән 23нче ноябренә кадәр | ОМС һәм учреждениеләр җитәкчеләре |
| 3. | Югары Ослан муниципаль районында коррупция турында халык фикерен өйрәнү буенча анкеталау. | 2018нчы елның 26нчы ноябреннән 30нчы ноябренә кадәр | Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, «Бердәм Россиянең Яшь гвардиясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының штаб начальнигы. |
| 4. | Ачык дәресләр, сыйныф сәгатьләре үткәрү. | 2018нчы елның 1нче декабреннән 9нчы декабренә кадәр | «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ |
| 5. | Өлкән сыйныф укучыларының хокук саклау органнары, иҗтимагый оешмалар һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре белән “Коррупция - Юк!” | 2018нчы елның 1нче декабреннән 9нчы декабренә кадәр | «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | темасына очрашулары. | | |
| 6. | Коррупциягә каршы тәрбия бирү мәктәпләрендә укучылар белән класстан тыш эш оештыру (әңгәмәләр, рольле уеннар, ата-аналар, хокук саклау органнары вәкилләре катнашында класс сәгатьләре). | 2018нчы елның 1нче декабреннән 9нчы декабренә кадәр | «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ |
| 7. | "Бирмәскә-алмаска", "Гадел булу модалы һәм дәрәҗәле" һәм башка девизы астында социаль акцияләр һәм чаралар оештыру һәм үткәрү. | 2018нчы елның 1нче декабреннән 9нчы декабренә кадәр | «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ |
| 8. | Коррупциягә каршы тематикага район китапханәләрендә (шул исәптән мәктәп китапханәләрендә) китап күргәзмәләре оештыру. | 2018нчы елның 1нче декабреннән 9нчы декабренә кадәр | «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ |
| 9. | Коррупциягә каршы юнәлешле конкурсларга йомгак ясау:<br><br>- рәсем конкурсы;<br><br>- иншалар конкурсы;<br><br>- плакатлар конкурсы;<br><br>- журналистлар конкурсы | 2018нче елның 7нче декабре | «Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ<br><br>«Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МК<br><br>«Татмедиа» АҖ, «Волжская Новь» газетасы редакциясе, коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе вәкиле |
| 10. | Муниципаль район сайтында, шулай ук район газетасында коррупциягә каршы юнәлештәге конкурслар, чаралар турында мәгълүмат урнаштыру. | Үткәрү чорында | Планның җаваплы башкаручылары |
| 11. | Коррупциягә каршы профилактика һәм аңа каршы тору буенча материалларны рәсми | Үткәрү чорында | Мәгълүматлаштыру бүлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сайтка урнаштыру. | | |